ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАРАКАШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Сирина Батыршина, д.33,
с.Каракашлы, 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Сирин Батыршин урамы, 33йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-34, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**№ 10** **09 апрель 2025 ел.**

*2025 елның язгы-җәйге чорына*
*икътисад өлкәсе объектлары һәм торак пунктларда*
*янгын куркынычсызлыгын арттыру чаралары турында*

1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ санлы «Янгын куркынычсызлыгы турында», 68-ФЗ санлы "Халыкны һәм территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында"гы Россия Федерациясе законнары нигезендә һәм янгын куркынычсызлыгын арттыру һәм кешеләрнең үлемен булдырмау, шулай ук янгыннар белән бәйле вәзгыятьне тотрыкландыру һәм 2025 елның язгы – җәйге чорына икътисад өлкәсе объектларын һәм торак пунктларны вакытында әзерләү максатларында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елның 21 апреленнән 11 маена кадәр Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим урнаштырырга.
2. Янгыннарны профилактикалау һәм җирлекнең икътисад өлкәсе объектларын һәм торак пунктларын язгы - җәйге янгын куркынычы чорына әзерләү чаралары планын (1 нче кушымта) расларга.
3. Объектларны язгы-җәйге чорда файдалануга әзерләргә, гадәттән тыш хәлләр һәм янгыннар килеп чыкмаслык тиешле чаралар күрергә.
4. Җирлек территориясендә, шәхси йорт яны участокларында чүп-чар һәм үлән яндыруны, учак ягуны, янгын куркынычы янаган эшләр башкаруны тыю.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Кәрәкәшле авыл җирлеге
Башлыгы урынбасары: З.Ә.Мәрданова

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Каракашлы авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2025 елның " 27 " мартындагы 10 номерлы
комитет карарына1 нче кушымта

**Янгыннарны профилактикалау һәм икътисад өлкәсе объектларын һәм торак пунктларны язгы – җәйге янгын куркынычы чорына әзерләү чаралары**

**ПЛАНЫ**

| № п/п | Чараның исеме | вакыты | җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | Җирлекнең икътисад өлкәсе объектларында һәм торак пунктларында янгынга каршы чаралар эшләргә һәм гамәлгә ашырырга | Апрель | Авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләре, җирлек Советы депутатлары |
| 2. | Янгын сүндерү һәм янгын сүндерүгә җайлаштырылган техниканы җәйге вакытта файдалануга әзерләргә. | Апрель | Авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләре |
| 3. | Җәйге каникулларга кадәр Кәрәкәшле төп гомуми белем бирү мәктәбендә «балаларның ут белән шаяртуыннан», янгыннарны кисәтү буенча эш алып барырга. | Май | Мәктәп директоры |
| 4. | Җирлекнең һәр торак пунктында янгын чыккан очракта су алу өчен урыннар әзерләргә. | Май | җирлек Советы депутатлары |
| 5. | Торак пунктларны тикшерүне оештырырга һәм үткәрергә, торак йортларны аңлату эшләре белән тикшерергә, нәтиҗәләр турында гражданнар җыеннарында фикер алышырга | Май -июнь | җирлек Советы депутатлары |
| 6. | Оешма җитәкчеләренә һәм гражданнарга объектларны янучан калдыклардан, чүп-чардан, савытлардан, коелган яфраклардан һәм коры үләннән вакытында чистартуны тәэмин итәргә | һәрдаим | җирлек Советы депутатлары |
| 7. | Су белән тәэмин итү юлларын, янгын гидрантларын тикшерүне оештырырга, аларны җәйге вакытта эксплуатацияләүгә әзерләргә | Май | Авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләре, җирлек Советы депутатлары |
| 8. | Урманчылыклар (Урман парклары) белән чиктәш, шулай ук торфлы туфраклы районнарда урнашкан яклау объектларын минераллаштырылган саклагыч полосалар булдыруны, язгы-җәйге чорда коры үсемлекләрне бетерүне һәм җыюны яисә табигый янгыннар вакытында ут таралуны кисәтә торган башка чаралар белән тәэмин итәргә. | Май -июнь | Авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләре, җирлек Советы депутатлары |